ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
КАРАРЫ

«Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 113 статьясындагы 4 өлешенең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты тәкъдимен исәпкә алып, «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты М.И. Галиевка кире кайтарырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 11 марты
№ 863-VI ДС